ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 311 « 30 » 03 2016 ел

Шәһәр һәм район территорияләрен чистарту
буенча санитар- экологик икеайлык
игълан итү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 03 мартында кабул ителгән б-452 нче номерлы боерыгын үтәү йөзеннән һәм торак пунктлары территорияләрен санитар чистартуны тәэмин итү һәм аларны халыкның экология һәм санитария эпидемиология иминлеге таләпләренә җавап бирә торган хәлгә китерүне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. 2018 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр шәһәр һүм район торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча санитария-экология икеайлыгын игълан итәргә.

2. Мамадыш муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетларына, Мамадыш шәһәре башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен язгы санитар чистарту һәм төзекләндерү буенча эшләрне координацияләү өчен оператив штаблар булдыру;

- 01 апрельгә кадәр авыл җирлекләрен һәм Мамадыш шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренә ярашлы рәвештә санитар-экологик хәлне яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар планын әзерләргә һәм расларга (1 нче кушымта)

- агач һәм куаклар утырту, юлларны һәм тротуарларны ремонтлау, йортларның фасадларын, урамнарны яктырту, зиратларны, пляжларны, скверларны, балалар мәйданчыкларын, азык-төлек һәм әйбер базарларын төзекләндерү, контейнер мәйданчыкларын төзү һәм ремонтлау, каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар әзерләү һәм ремонтлау һ.б.

- предприятиеләр, учреждениеләр һәм башка оешмалар җитәкчеләрен һәм халыкны шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен язгы санитар чистартуны уздыру турында мәгълүмат җиткерергә;

- җирле халык һәм укучылар катнашында киң булган предприятиеләр һәм оешмалар катнашында транспорт чараларын һәм юл-төзелеш механизмнарын җәлеп итеп, торак пунктлар территорияләрен санитар чистарту буенча

массакүләм шимбә өмәләре оештырырга;

- йорт биләмәләре территориясендәге көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны, аларның ведомстволы булуларына бәйсез рәвештә, сәнәгать предприятиеләре, төзелеш оешмалары, базарлар, дәвалау, сәүдә учреждениеләре һәм мәдәни-көнкүреш билгеләнешендәге оешмалар территорияләреннән вакытында алуны тәэмин итү буенча кирәкле чаралар күрергә;

- җирлекләрнең һәм шәһәрнең территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренең үтәлешен контрольдә тотуны көчәйтү өлешендә административ комиссия эшен активлаштырырга, шулай ук язгы санитар чистарту һәм шәһәрне һәм районны төзекләндерү барышында рейд тикшерүләрен контроль органнары белән берлектә оештырырга һәм уздырырга.;

- терлекчелек комплекслары калдыкларын рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү буенча чаралар күрергә;

- «Татарстан Республикасы Экологик картасы» геомәгълүмат системасы www.ecokarta.tatar.ru ярдәмендә ведомство буйсынуындагы территориядә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү мониторингын гамәлгә ашырырга»;

- ведомство буйсынуындагы территорияләрне санитар-экологик чистарту эшенә иҗтимагый (волонтерлык) оешмаларын җәлеп итәргә;

- районның мәшгульлек үзәгендә эшсезлек буенча хисапта торучы эшсезләрне ведомствога буйсынучы территорияләрне санитар-экологик чистарту эшенә җәлеп итәргә.

3. «Мамадыш ЖКУ»ҖЧҖ түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- Каты көнкүреш калдыкларын кабул итү, сортларга аеру һәм күмү буенча эш алып барырга, чүп чыгару өчен махсус машина паркы һәм чүп полигоннарының нәтиҗәле эшен тәэмин итәргә.

4. Шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә, «Мамадыш ЖКУ» ҖЧҖ җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- каты көнкүреш, биологик калдыклар (үләт базларын) полигоннарын һәм санкцияләнгән чүплекләр, вакытлыча файдаланудагы җитештерү һәм көнкүреш калдыклары урыннарын һәм аларга юллар тиешле санитар хәлгә китерергә.

5. ОАО ПРСО «Татавтодор» Мамадыш филиалына гомуми файдаланудагы региональ әһәмиятле автомобиль юлларының, транспорт комплексының башка объектларының юл буе полосаларының санитар-экологик торышын нәтиҗәле тикшереп торуны тәэмин итәргә.

6. Мамадыш районында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиологик иминлек буенча ведомствоара комиссиягә (Дәрҗеманов И.М.) Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы Мамадыш районы һәм Мамадыш шәһәре буенча территориаль идарәсе (Мәснәвиева М.Х) Мамадыш шәһәре һәм районның авыл җирлекләре территориясендә сәнәгать һәм көнкүреш калдыклары белән эш итүне җайга салу өлкәсендә контрольне көчәйтергә.

7. Мамадыш районында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиологик иминлек буенча ведомствоара комиссиягә (Дәрҗеманов И.М.) Предложить Межведомственной комиссии по

экологической безопасности, природопользованию и санитарно-эпидемиологическому благополучию в Мамадышском районе (Дарземанов И.М.) Шәһәр һәм район территорияләрен санитар чистарту һәм төзекләндерү эшләрен координацияләү, шулай ук Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына атна саен 1 нче номерлы формада икеайлыкны үткәрү барышы турында мәгълүмат (аңлатма язуы белән) - 13, 27 апрель, 11, 25 май, 2013 елның 21 мартындагы 452-р номерлы ТР Министрлар Кабинеты карарына кушымта нигезендә бирүне тәкъдим итәргә.

8. Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (С.Н.Ханова) ике айлык кысаларында үткәрелә торган эшне “Нократ” (“Вятка”) газетасында киң күләмдә яктыртып торуны тәэмин итәргә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.М. Дәрземановка йөкләргә.

Җитәкче С.М.Гыймранов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
30.03. 2016 ел, № 311 карарына
1 нче кушымта

# Мамадыш муниципаль районында санитар-экологик хәлне яхшыртуга юнәлтелгән чаралар планы

| № п/п | Эшләр исеме | Үлчәү берәмлеге | 01.04.2016 - 31.05.2016 еллар чорына эш планы. |
|---|---|---|---|
| 1. | Эшкә җәлеп ителгән оешмалар һәм предприятиеләр саны, барлыгы: | ед. | 280 |
| | Шул исәптән ЖКХ | ед. | 1 |
| 2. | Якын территорияләрне җыештырырга: | | |
| | Торак йортлар янында | ед. | 128 |
| | М-7федераль юлда | км | 44,4 |
| | территориаль әһәмияттәге юлларга | км | 334 |
| 3. | Утыртырга: | | |
| | агачлар | шт. | 1200 |
| | куаклар | шт. | 2800 |
| 4. | Санитар кисү: | | |
| | агачлар | шт. | 1200 |
| | Куаклар | шт. | 1500 |
| 5. | ремонтларга: | | |
| | куркынычсызлык коймалары | п.м | 1000 |
| | Йорт фасадлары | куб.м | 3000 |
| | Балалар мәйданчыклары | шт. | 25 |
| 6. | Урам яктырткычларын буярга | шт. | 3000 |
| 7. | ПГС һәм вак таш әзерләргә | куб.м | 500 |
| 8. | ККК чыгару | куб.м | 5000 |
| 9. | Махсус автотранспортны җәлеп итү | шт. | 50 |
| 10. | Контейнер мәйданчыклары саны | шт. | 259 |
| | шул исәптән яңаларын төзү | шт. | 10 |
| 11. | Контейнерлар саны, Барлыгы: | шт. | 490 |
| | Шул исәптән: | | |
| | төзекләндерелгән | шт. | 30 |
| | Яңалар куелган | шт. | 30 |
| 12. | Халыкны җәлеп итү | чел. | 15000 |
| 13. | Биологик калдыкларны утильләштерү урыннарын төзекләндерү: | | |
| | биотермик чокырлар | шт. | 30 |
| | Себер язвасы белән күмелгән | шт. | 2 |

Җитәкче урынбасары И.М. Дәрҗеманов